КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 декабрь г.Казань № 1163

«Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклау һәм үстерү буенча мәгариф оешмаларына һәм иҗтимагый оешмалар инициативаларына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклау һәм үстерү буенча мәгариф оешмаларына һәм иҗтимагый оешмалар инициативаларына ярдәм күрсәтү» грантын гамәлгә куярга.
2. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклау һәм үстерү буенча мәгариф оешмаларына һәм иҗтимагый оешмалар инициативаларына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
3. Бу карар (әлеге Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 27 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин